**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 10 декабрь № 938

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Туристлык индустриясе объектларын классификацияләүне гамәлгә ашыра торган оешмаларны аккредитацияләү буенча вәкаләтле орган турында» 2011 ел, 29 август, 726 нчы карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Туристлык индустриясе объектларын классификацияләүне гамәлгә ашыра торган оешмаларны аккредитацияләү буенча вәкаләтле орган турында» 2011 ел, 29 август, 726 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 июнь, 381 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

карарның преамбуласын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Кунакханәләрне һәм башка урнаштыру урыннарын, тауда чаңгы шуу трассаларын һәм пляжларны үз эченә алган туристлык индустриясе объектларын классификацияләүне гамәлгә ашыра торган оешмаларны аккредитацияләү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 29 апрель, 1340 нчы боерыгы белән расланган Кунакханәләрне һәм башка урнаштыру чараларын, тауда чаңгы шуу трассаларын һәм пляжларны үз эченә алган туристлык индустриясе объектларын классификацияләүне гамәлгә ашыра торган оешмаларны аккредитацияләү тәртибе нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\938.docx